| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН САРМАНОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16 декабрь 2025 ел № 12

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында" 03.10.2025 елгы 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Әлмәт авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советының 2022 елның 14 февралендәге 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (Советның 25.11.2022 елгы 22 нче, 22.02.2023 елгы 1 нче, 05.04.2023 елгы 4 нче, 08.08.2023 елгы 11, 24.11.2023 N 15, 29.12.2023 N 23, 25.03.2024 № 1, 20.06.2024 № 5, 02.11.2024 № 11.22.11.2024 № 16, 07.02.2025 елгы 2 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.5 пунктның 2,3 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу - вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен; югары белем яисә урта һөнәри белем булу - авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

- муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

-муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.".

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» халыкка җиткерергә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Советы Рәисе Д.Ә.Газизов

.